КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1262

«Регби буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында

Балалар һәм яшүсмерләр арасында физик культура һәм массакүләм спортны үстерү, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең регби буенча җыелма командаларына спорт резервын әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының, Татарстан Республикасында регби үстерүне төп эшчәнлек максаты итеп билгеләп, «Регби буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

60 көн эчендә Учреждение уставын расларга һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән күздә тотылган кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

үз норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә;

Учреждение уставы расланган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Раунс Гәрәев урамы, 76 нчы йорт адресы буенча урнашкан Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле мөлкәт, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен Учреждение өчен аның уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек төре нигезендә дәүләт йөкләмәсен расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Учреждениенең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы гамәлгә ашыра;

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәү буенча эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт бюджет учреждениеләре, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы эшчәнлеген тәэмин итүгә каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла;

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан кертелгәннән соң 30 көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында Учреждениегә билгеләнгән тәртиптә беркетергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән берлектә, Учреждениенең уставы расланган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга спорт төрләре буенча спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 874 нче карарына үзгәрешләр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин